| | | |
|---|---|---|
| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |

ПРИКАЗ БОЕРЫК

27.05.2020 Казан ш. № 55

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 июнендәге 37 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 июнендәге 37 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карарлар кабул итү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләттерүгә түбәндәге очракларда шаныч юк дип таныла:

1) физик зат – бюджетка түләүләр түләүче зат вафат булганда яисә Россия Федерациясенең граждани-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгәндә;

2) мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле түләнмәгән бурычы өлешендә «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ

номерлы федераль закон нигезендә шәхси эшкуар – бюджетка түләүләр түләүче зат банкрот дип танылганда;

2.1) «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисап ясалганнан соң бюджетка түләүләр буенча түләнеп бетмәгән әҗәте өлешендә шәхси эшкуар булып тормаган гражданин «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип танылган очракта;

3) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча әҗәте өлешендә оешма – бюджетка түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

4) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә;

5) суд приставы-башкаручысы тарафыннан «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару эшчәнлегенең тәмамлануы һәм түләттерүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан башлап биш елдан күбрәк вакыт узса, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме әҗәтле затка карата банкротлык турында эш кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

бюджетка түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яисә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турында эш туктатылганда;

6) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча әҗәте өлешендә теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган

очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча әҗәт бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш;

7) түләнмәгән административ штрафлар, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен ышанычсыз дип танылa.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

1) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыкка килүне раслый торган документлар;

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында Инспекция хисапларыннан өземтәләр;

3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерелүен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында, раслый торган документларны теркәп, Инспекция белешмәләре;

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерүгә ышанычсыз булуын тануның әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән очракларын раслый торган документлар:

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

физик зат – түләүченең вафат булуын таныклый торган яисә аның вафат дип игълан ителүе турында дәлилләүче документ (күчермәсе);

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Шәхси эшкуар – бюджетка түләүләр түләүче затның банкрот дип танылуына бәйле рәвештә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан аның эшчәнлеге туктатылу турындагы белешмәләрне үз эченә ала торган документ;

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

«Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисап ясалганнан соң бюджетка түләүләр буенча түләнеп бетмәгән әҗәте өлешендә шәхси эшкуар булып тормаган гражданинны «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип тануны раслый торган документ;

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан оешма – бюджетка түләүләр түләүче затның бетерелүенә бәйле рәвештә аның эшчәнлеге туктатылуы турындагы белешмәләрне үз эченә ала торган документ;

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында законлы көченә кергән акт күчермәсе яки бюджет керемнәре

администраторы бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карарының кабул ителүе турында законлы көченә кергән суд билгеләмәсе күчермәсе;

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

«Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча суд приставы-башкаручысының башкару эшчәнлегенең тәмамлануы һәм башкару документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе турындагы карары күчермәсе;

бөлгенлек турындагы эш буенча эш кузгату өчен нигезләр булмавы турында белешмә күчермәсе;

бурычлы затны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтарып бирү турында яисә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрү өчен суд чыгымнарын түләү өчен җитәрлек дәрәҗәдә акча булмауга бәйле рәвештә банкротлык турындагы эшнең туктатылуы турында суд билгеләмәсе күчермәсе (әгәр бурыч күләме банкротлык турындагы эш буенча эш кузгату өчен Россия Федерациясенең бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарында бурычлыга карата билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китсә).

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча әҗәте өлешендә теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик затның Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылуы һәм, «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар турында белешмәләрне үз эченә алган документ. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча әҗәт бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш;

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 7 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

административ җәза билгеләү турында карар үтәлешен туктату турында законлы көченә кергән суд актының яки, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турында карар чыгарган башка органның, вазыйфаи затның документы (карары) күчермәсе.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча түләттерү өчен ышанычсыз дип танылырга тиешле әҗәт булуы турында мәгълүмат,

әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган документларны теркәп, Инспекциянең административ тәҗрибә һәм өлешле төзелешне тикшереп тору бүлеге, юридик бүлеге, территориаль органнары тарафыннан Комиссиягә җибәрелә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Инспекция белешмәләре расланган документлар алынганнан соң бер ай эчендә Инспекциянең административ тәҗрибә бүлеге, юридик бүлеге, территориаль органнары тарафыннан Комиссиягә җибәрелә;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында Инспекция хисапларыннан өземтәләр аларны алганнан соң 5 эш көне эчендә Инспекциянең финанс-икътисад контроле бүлеге тарафыннан Комиссиягә җибәрелә»;

Әлеге боерык белән расланган банкротлык турында эш кузгату өчен нигезләр булмавы турындагы белешмәне яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең территориаль органнары, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе вазыйфаи затларына җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасының
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 05.06.2017
№ 37 боерыгы белән расланды
(Инспекциянең 27.05.2020 № 55
боерыгы редакциясендә)

Форма

Банкротлык эше буенча эш кузгату өчен нигезләр булмавы турында
белешмә

Дата

«Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча _______________ карата ___________ №___ эш буенча башкару эшчәнлегенең төгәлләнүе турында пристав-башкаручы тарафыннан карар чыгарылуга бәйле рәвештә, Хокук идарәсе тарафыннан _________________________________________ карата банкротлык эше буенча эш кузгату турындагы мәсьәлә карап тикшерелде.

___________ № _____ административ хокук бозу эше турындагы карар буенча бурыч күләме __________ сум тәшкил иткәнгә күрә һәм банкротлык эше буенча эш кузгату өчен бурычлы затка карата Россия Федерациясенең бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәвенә бәйле рәвештә, ___________________________________ карата банкротлык турында эш кузгату өчен нигезләр юк.

___________ №____ административ хокук бозу эше турындагы карар буенча _________________ күләмендәге ______________ бурыч, ___________ бурыч барлыкка килү датасыннан башлап биш ел узгач, түләттерү өчен ышанычсыз дип танылырга мөмкин.

Вазыйфа _______________________/______________/.
(Ф.И.А.) (имза)